СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«28» декабрь, 2023 ел        Алабуга шәһәре        № 323

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне һәм коррупциягә каршы көрәш тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану турында» 2013 елның 7 февралендәге 290 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2013 елның 7 февралендәге 290 номерлы карары белән расланган, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне һәм коррупциягә каршы көрәш тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, дисциплинар җәзаларны куллану һәм алу тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә.

1.1. Нигезләмәнең 1.15 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырсалар, яисә белә торып тулы булмаган белешмәләрне тапшырмау муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора, моңа федераль законнарда билгеләнгән очраклар керми.»;

1.2. Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль хезмәткәрләргә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрү;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары — Р.Л. Исланов